ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.10.2019 г. Заинск № 552

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә шәһәр яны элемтәсе муниципаль маршруты буенча автомобиль транспортында көйләүле тарифлар буенча даими төстә пассажирлар һәм багаж йөртүне гамәлгә ашыру белән бәйле эшләрне башкару чыгымнарын өлешчә кире кайтару максатында, пассажирлар ташучыларга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында” Зәй муниципаль районы башкарма комитетының 1212нче карарына (23.07.2018) үзгәрешләр кертү турында”**

Россия Федерациясе бюджет кодексының 47.2 маддәсе (31.07.1998, 145нче ФЗ) нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставына таянып, муниципаль район башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. ”Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә шәһәр яны элемтәсе муниципаль маршруты буенча автомобиль транспортында көйләүле тарифлар буенча даими төстә пассажирлар һәм багаж йөртүне гамәлгә ашыру белән бәйле эшләрне башкару чыгымнарын өлешчә кире кайтару максатында, пассажирлар ташучыларга субсидияләр бирү Тәртибен раслау турында” карарының (Муниципаль район башкарма

комитетының 1756нчы (23.11.2018); 61нче (20.02.2019); 427нче (12.08.2019); 538нче (10.10.2019) карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) 1нче кушымтасындагы 10нчы абзац 5.1 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

"Шул ук вакытта пассажир ташучының керемнәре транспорт чарасының тулылану күрсәткеченнән чыгып 50 процентан да ким булмаган күләмдә исәпләнә"

2. Әлеге карарны муниципаль районның рәсми сайтында (http://zainsk.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

3. Карар 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Карарның үтәлешенә күзәтчелек итүне башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары Н.А. Нифатовка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Ф. Хафизов**